КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 12 май г.Казань № 434

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында физик культура һәм спортны үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 ел, 5 март, 159 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2022 елларга Татарстан Республикасында физик культура һәм спортны үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 ел, 5 март, 159 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 12 июль, 567 нче; 2019 ел, 8 ноябрь, 1023 нче 2019 ел, 30 декабрь, 1279 нчы 2020 ел, 12 июнь, 483 нче; 2020 ел, 11 декабрь, 1117 нче; 2021 ел, 9 август, 693 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «2019 - 2022» саннарын «2019 - 2025» саннарына алмаштырырга;

1 пунктта «2019 - 2022» саннарын «2019 - 2025» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында физик культура һәм спортны үстерү» дәүләт программасында (алга таба – Программа):

исемендә «2019 - 2022» саннарын «2019 - 2025» саннарына алмаштырырга;

Программа паспортында:

«Программа исеме» юлында «2014 - 2024» саннарын «2014 - 2027» саннарына алмаштырырга;

«Программаны гамәлгә ашыру сроклары» юлында «2014 - 2024» саннарын «2014 - 2025» саннарына алмаштырырга;

«Ярдәмче программалар исемлеге» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Ярдәмче программалар исемлеге | 1. «2019 - 2025 елларга физик культура һәм массакүләм спортны үстерү».<br>2. «2019 - 2025 елларга югары казанышлар спортын һәм спорт резервын әзерләү системасын үстерү».<br>3. «2019 - 2025 елларга физик культура һәм спорт өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерү».<br>4. «2019 – 2025 елларга Татарстан Республикасында физик культураны һәм спортны үстерү» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү» |

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре | 2019 – 2025 елларда Программаны финанслауның гомуми күләме 36 240 091,53 мең сум тәшкил итәчәк, шулардан:<br>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 33 150 431,82 мең сум, шул исәптән:<br>2019 елда - 4 417 725,9 мең сум;<br>2020 елда - 8 210 218,98 мең сум;<br>2021 елда - 5 538 758,84 мең сум;<br>2022 елда - 3 748 269,7 мең сум;<br>2023 елда - 3 876 047,0 мең сум;<br>2024 елда - 3 679 705,7 мең сум;<br>2025 елда - 3 679 705,7 мең сум;<br>җәлеп итүгә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы исәбеннән - 3 043 659,71 мең сум, шул исәптән:<br>2019 елда - 401 646,7 мең сум;<br>2020 елда - 823 315,5 мең сум;<br>2021 елда - 316 737,7 мең сум;<br>2022 елда - 498 709,8 мең сум;<br>2023 елда - 919 062,6 мең сум;<br>2024 елда - 42 093,7 мең сум;<br>2025 елда - 42 093,7 мең сум;<br>җәлеп итүгә планлаштырыла торган бюджеттан тыш чыганаклардан акча исәбеннән - 46 000,0 мең сум, шул исәптән:<br>2019 елда – 0,0 мең сум;<br>2020 елда - 0,0 мең сум;<br>2021 елда – 0,0 мең сум;<br>2022 елда - 0,0 мең сум;<br>2023 елда – 46 000,0 мең сум;<br>2024 елда – 0,0 мең сум;<br>2025 елда – 0,0 мең сум.<br>Программаны финанслау күләмнәре фараз характерында һәм тиешле финанс елына һәм план чорына бюджет проектын |

| | |
|---|---|
| | формалаштырганда ел саен тәгаенләнергә тиеш.<br>Федераль бюджет, җирле бюджетлар һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчасы күләмнәре ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк»; |

«Программаның максатын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Программаның максатын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Программа чараларын тормышка ашыру 2025 елга түбәндәгеләрне арттыруга ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>физик культура һәм спорт белән системалы рәвештә шөгыльләнүче Татарстан Республикасы гражданнарының өлешен 62,1 процентка кадәр;<br>«Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексының сынаулар (тестлар) нормативларын тапшыруда катнашкан халыкның гомуми санында «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексының сынаулар (тестлар) нормативларын үтәгән Татарстан Республикасы халкы өлешен 57,5 процентка кадәр;<br>сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затлар һәм инвалидларның гомуми санында физик культура һәм спорт белән системалы рәвештә шөгыльләнүче әлеге категориядәге затлар өлешен 30,0 процентка кадәр;<br>физик культура һәм спорт өлкәсендәге оешмаларның гомуми санында, шул исәптән сәламәтлеге һәм инвалидлары мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен спорт әзерлегенең федераль стандартлары нигезендә спорт әзерлеге буенча хезмәтләр күрсәтүче оешмалар өлешен 100 процентка кадәр;<br>спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда спортны камилләштерү этабында шөгыльләнүчеләрнең гомуми санын 25,0 процентка кадәр;<br>Россия Федерациясе спорт җыелма командаларына кандидатлар исемлекләренә кертелгән спортчыларның санын 580 кешегә кадәр;<br>гражданнарның спорт корылмалары белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен, бер мәртәбә үткәрү сәләтеннән чыгып, 71,2 процентка кадәр;<br>100 мең кешегә исәпләнгән спорт корылмалары санын 323 берәмлеккә кадәр;<br>спорт учреждениеләрен тәэмин итү өчен электр энергиясенең |

| | |
|---|---|
| | чагыштырма чыгымын (җылытыла торган 1 кв.метр мәйданга исәпләгәндә) – 1 кв.метрга 71,44 кВт × сәгать;<br>спорт учреждениеләрен тәэмин итү өчен җылылык энергиясенең чагыштырма чыгымын (җылытыла торган 1 кв.метр мәйданга исәпләгәндә) – җылытыла торган 1 кв.метр мәйданга 0,103 Гкал;<br>спорт учреждениеләрен тәэмин итү өчен салкын суның чагыштырма чыгымын (1 кешегә (персонал һәм йөрүчеләргә) исәпләгәндә) – 1 кешегә (персонал һәм йөрүчеләргә) 0,157 куб.метр;<br>спорт учреждениеләрен тәэмин итү өчен табигый газның чагыштырма чыгымын (газ белән җылытыла торган мәйданның 1 кв.метрына исәпләгәндә) – газ белән җылытыла торган мәйданның 1 кв.метрына 23,91 куб.метр;<br>Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының мәҗбүри энергетика тикшерүен үткән ведомство буйсынуындагы учреждениеләре (урыннарны арендага алучы учреждение-ләрне исәпкә алмыйча) өлешен 100 процентка кадәр;<br>Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының исәпкә алу приборлары белән җиһазландырылган ведомство буйсынуын-дагы учреждениеләре (урыннарны арендага алучы учрежде-ниеләрне исәпкә алмыйча) өлешен 100 процентка кадәр»; |

Программаның I бүлегендә:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Программа «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законны, «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» 2007 елның 4 декабрендәге 329-ФЗ номерлы Федераль законны, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Уңайлы мохит» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2019 елның 29 мартындагы 363 номерлы карарын, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 24 ноябрендәге 3081-р номерлы боерыгын, Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе Д.А.Медведевның тарафыннан расланган 2018 елның 29 сентябрендәге 8028-П13 номерлы 2024 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе Хөкүмәте эшчәнлегенең төп юнәлешләрен, «Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын, «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 - 2025 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 23 декабрь, 1023 нче карарын исәпкә алып эшләнде.»;

кырык сигезенче һәм кырык тугызынчы абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2019 - 2025 елларга физик культураны һәм спортны үстерү» ярдәмче программасы кысаларында әлеге проблемаларны хәл итү өчен спорт

инфраструктурасын һәм спорт учреждениеләре челтәрен үстерүгә, аларның эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрүгә, массакүләм балалар һәм яшүсмерләр спортын үстерүгә һәм спорт резервын әзерләүгә, студентлар спортын үстерүгә, халыкның барлык категорияләре арасында массакүләм спортны үстерүгә, спортның өстенлекле төрләрен үстерүгә, югары классլы спортчыларны әзерләүгә шартлар тудыруга, физик культура һәм спорт буенча белгечләр әзерләүгә ярдәм итүгә, халыкның физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүгә ихтыяҗын формалаштыруга, халыкның сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга, физик культура һәм спорт өлкәсен фәнни, мәгълүмати-методик тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар комплексы тәкъдим ителә.

Физик культура һәм спорт өлкәсен үстерү буенча республика һәм федераль программаларны гамәлгә ашыру кысаларында динамикада программаларны гамәлгә ашыруның иң мөһим нәтиҗәсе булып, системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче республика халкының чагыштырма авырлыгын арттыру 2025 ел ахырына 62,1 процентка кадәр булачак.»;

Программаның II бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. Программаның төп максаты һәм бурычлары, программа чаралары, көтелә торган соңгы нәтиҗәләрнең тасвирламасы, аны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары

Программаның максаты – Татарстан Республикасында физик культура һәм спорт өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру.

Куелган максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү күздә тотыла:

1. Татарстан Республикасы халкының физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүгә мотивациясен арттыру, сәламәт яшәү рәвешен алып бару.

2. Спорт резервын әзерләү системасын камилләштерү һәм Татарстан Республикасы спортчыларының регионара, бөтенроссия ярышларында һәм Россия Федерациясе җыелма командалары составында эре халыкара спорт ярышларында уңышлы чыгыш ясауларын тәэмин итү.

3. Физик культура һәм спорт өлкәсендә дәүләт сәясәтенең нәтиҗәлелеген арттыру.

4. Спорт һәм инженерлык инфраструктурасын ныгыту, шулай ук спорт корылмаларының энергетик нәтиҗәлелеген арттыру.

Куелган максатның масштаблылыгы чаралар комплексын эшләүне таләп итә.

Физик культураны һәм массакүләм спортны үстерү, халыкның сәламәтлеген ныгыту, Татарстанның спорт имиджын ныгыту өчен «2019 - 2025 елларга физик культураны һәм массакүләм спортны үстерү» ярдәмче программасы гамәлгә ашырыла.

Ярдәмче программа сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга, сәламәтлекне ныгытуга, халыкның барлык яшь төркемнәренең физик активлыгын һәм әзерлеген күтәрүгә, тулысынча ял итү һәм сәламәт ял итү өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән чараларны үтәүне күздә тота.

Күрсәтелгән чараларны гамәлгә ашыру Татарстан Республикасы халкының сәламәтлеген ныгыту өчен шартлар тудырырга, республикадагы демографик вәзгыятьне яхшыртырга, массакүләм спортны үстерергә һәм популярлаштырырга,

Татарстанның спорт имиджын киләчәктә халыкара дәрәҗәдә ныгыту максатларында җәмгыятьнең төрле катламнарын физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүгә җәлеп итәргә мөмкинлек бирәчәк.

Ярдәмче программа чараларын тормышка ашыру 2025 елга түбәндәгеләрне арттыруга ирешергә мөмкинлек бирәчәк:

физик культура һәм спорт белән системалы рәвештә шөгыльләнүче Татарстан Республикасы гражданнарының өлешен 62,1 процентка кадәр;

«Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексының сынаулар (тестлар) нормативларын тапшыруда катнашкан халыкның гомуми санында «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексының сынаулар (тестлар) нормативларын үтәгән Татарстан Республикасы халкы өлешен 57,5 процентка кадәр;

сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затлар һәм инвалидларның гомуми санында физик культура һәм спорт белән системалы рәвештә шөгыльләнүче әлеге категориядәге затлар өлешен 30,0 процентка кадәр;

Спорт резервын әзерләүне һәм Татарстан Республикасы спортчыларының Россия һәм халыкара спорт ярышларында уңышлы чыгышларын тәэмин итү максатларында «2019 - 2025 елларга спорт резервын әзерләү һәм югары казанышлар спортын үстерү» ярдәмче программасы гамәлгә ашырыла.

Ярдәмче программа спорт резервын әзерләүгә, спорт мәктәпләрендә укучыларның спорт нәтиҗәләрен камилләштерүгә, физик культура һәм спорт өлкәсендәге эшчәнлекне фәнни, аналитик һәм методик яктан тәэмин итү системасына ярдәм итүгә, спорт юнәлешендәге балаларга һәм һөнәри белем бирү оешмаларына өстәмә белем бирү оешмаларына ярдәм итүгә, югары казанышлар спорты (профессиональ спорт) спортын үстерүгә юнәлдерелгән чараларны үтәүне күздә тота.

Ярдәмче программа чараларын тормышка ашыру 2025 елга түбәндәгеләрне арттыруга ирешергә мөмкинлек бирәчәк:

Россия Федерациясе спорт җыелма командаларына кандидатлар исемлекләренә кертелгән спортчыларның санын 580 кешегә кадәр;

физик культура һәм спорт өлкәсендәге оешмаларның гомуми санында, шул исәптән сәламәтлеге һәм инвалидлары мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен спорт әзерлегенең федераль стандартлары нигезендә спорт әзерлеге буенча хезмәтләр күрсәтүче оешмалар өлешен 100 процентка кадәр;

спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда спортны камилләштерү этабында шөгыльләнүчеләрнең гомуми санын 25 процентка кадәр;

Татарстан Республикасы халкының сәламәтлеген ныгыту, республикадагы демографик вәзгыятьне яхшырту, массакүләм спортны һәм югары казанышлар спортын (һөнәри спортны) үстерү һәм популярлаштыру, җәмгыятьнең төрле катламнарын физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүгә җәлеп итү, Татарстанның спорт имиджын халыкара дәрәҗәдә ныгыту, күзәтүчесезлекне, экстремизмны, хокук бозуларны, тәмәке тартуны, алкоголизмны, наркоманияне һәм башка социаль-тискәре күренешләрне профилактикалау, шулай ук «2019 - 2025 елларга Татарстан Республикасында физик культура һәм спортны үстерү»

дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру каралган.

Күрсәтелгән ярдәмче программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге түбәндәге индикаторлар белән бәяләнә:

100 мең кешегә исәпләнгән спорт корылмалары саны, берәмлек;

гражданнарның спорт корылмалары белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе, бер мәртәбә үткәрү сәләтеннән чыгып, процентлар;

спорт учреждениеләрен (гомуми мәйданның 1 кв.метрына исәпләгәндә), бер кв.метрга кВт×сәг электр энергиясен тәэмин итүгә чагыштырма чыгымнар;

спорт учреждениеләрен (җылылык энергиясе белән җылытыла торган мәйданның 1 кв. метрына исәпләгәндә), җылылык энергиясе белән җылытыла торган мәйданның 1 кв. метрына исәпләнгән җылылык энергиясенең чагыштырма чыгымы;

спорт учреждениеләрен тәэмин итү өчен салкын суның чагыштырма чыгымы (1 кешегә (персонал һәм йөрүчеләргә) исәпләгәндә) – 1 кешегә (персонал һәм йөрүчеләргә) куб.метр;

спорт учреждениеләрен тәэмин итүгә табигый газның чагыштырма чыгымы (газ җылыта торган мәйданның 1 кв.метрына исәпләгәндә) - газ ягып җылытыла торган мәйданның 1 кв.метрына;

мәҗбүри энергетика тикшерүен узган Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына буйсынучы учреждениеләр өлеше (биналарны арендалаучы учреждениеләрне исәпкә алмыйча), процент;

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына караган учреждениеләрнең исәпкә алу җайланмалары белән җиһазландырылган өлешләре (бинаны арендага алучы учреждениеләрне исәпкә алмыйча), процент.

Программаның максаты, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм Программа чаралары буенча финанслау аңа теркәлгән кушымтада китерелде.

Программаны тормышка ашыруның гомуми срогы: 2019 – 2025 еллар.»;

Программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

2019 – 2025 елларда Программаны финанслауның гомуми күләме 36 240 091,53 мең сум тәшкил итәчәк, шулардан:

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 33 150 431,82 мең сум, шул исәптән:

2019 елда - 4 417 725,9 мең сум;

2020 елда - 8 210 218,98 мең сум;

2021 елда - 5 538 758,84 мең сум;

2022 елда - 3 748 269,7 мең сум;

2023 елда - 3 876 047,0 мең сум;

2024 елда - 3 679 705,7 мең сум;

2025 елда - 3 679 705,7 мең сум;

җәлеп итүгә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы исәбеннән - 3 043 659,71 мең сум, шул исәптән:

2019 елда - 401 646,7 мең сум;
2020 елда - 823 315,5 мең сум;
2021 елда - 316 737,7 мең сум;
2022 елда - 498 709,8 мең сум;
2023 елда - 919 062,6 мең сум;
2024 елда - 42 093,7 мең сум;
2025 елда - 42 093,7 мең сум;

җәлеп итүгә планлаштырыла торган бюджеттан тыш чыганаклардан акча исәбеннән - 46 000,0 мең сум, шул исәптән:

2019 елда – 0,0 мең сум;
2020 елда - 0,0 мең сум;
2021 елда – 0,0 мең сум;
2022 елда - 0,0 мең сум;
2023 елда – 46 000,0 мең сум;
2024 елда – 0,0 мең сум;
2025 елда – 0,0 мең сум.

Программаны финанслау күләмнәре фараз характерында һәм тиешле финанс елына һәм план чорына бюджет проектын формалаштырганда ел саен тәгаенләнергә тиеш.

Федераль бюджет, җирле бюджетлар һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчасы күләмнәре ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк.»;

Программаның кушымтасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

«2019 - 2024 елларга физик культураны һәм массакүләм спортны үстерү» ярдәмче программасында (алга таба - 1 нче ярдәмче программа):

1 нче ярдәмче программа исемендә «2019 - 2024» саннарын «2019 - 2025» саннарына алмаштырырга;

1 нче ярдәмче программа паспортында:

«Ярдәмче программа исеме» юлында «2019 - 2024» саннарын «2019 - 2025» саннарына алмаштырырга;

«1 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру сроклары» юлында «2019 - 2024» саннарын «2019 - 2025» саннарына алмаштырырга;

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, 1 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, 1 нче ярдәмче программны финанслау күләмнәре | 1 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 1 367 880,3 мең сум тәшкил итәчәк, шулардан Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән - 1 177 595,2 мең сум, шул исәптән:<br>2019 елда - 318 916,6 мең сум;<br>2020 елда - 144 457,6 мең сум;<br>2021 елда - 300 996,9 мең сум;<br>2022 елда - 102 756,4 мең сум;<br>2023 елда - 103 214,7 мең сум;<br>2024 елда - 103 626,5 мең сум; |

| | |
|---|---|
| | 2025 елда - 103 626,5 мең сум.<br>Федераль бюджет акчасы исәбеннән планлаштырыла торган финанслау 190 285,1 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>2019 елда - 69 341,1 мең сум;<br>2020 елда - 45 478,3 мең сум;<br>2021 елда - 14 868,9 мең сум;<br>2022 елда - 20 870,3 мең сум;<br>2023 елда - 21 353,1 мең сум;<br>2024 елда - 9 186,7 мең сум;<br>2025 елда - 9 186,7 мең сум.<br>1 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен тәгаенләнергә тиеш.<br>Федераль бюджет, җирле бюджетлар һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчасы күләмнәре ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк»; |

«1 нче ярдәмче программаның максатын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «1 нче ярдәмче программаның максатын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | 1 нче ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыру 2025 елга физик культура һәм массакүләм спорт өлкәсендә түбәндәгеләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче гражданнар өлешен 62,1 процентка кадәр;<br>«Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексының сынаулар (тестлар) нормативларын тапшыруда катнашкан халыкның гомуми санында «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексының сынаулар (тестлар) нормативларын үтәгән Татарстан Республикасы халкы өлеше 57,5 процентка кадәр, шулардан укучылар һәм студентлар өлешен 71,0 процентка кадәр;<br>сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затлар һәм инвалидларның гомуми санында физик культура һәм спорт белән системалы рәвештә шөгыльләнүче әлеге категориядәге затлар өлешен 30,0 процентка кадәр;<br>Татарстан Республикасы халкының гомуми санында даими рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче авыл халкы өлеше 58,3 процентка кадәр;<br>системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче балалар һәм яшьләр өлешен (3 - 29 яшь) 88,5 процентка кадәр; |

| | |
|---|---|
| | системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче гражданнарның өлешен (хатын-кызлар 30 - 54 яшь, ир-атлар 30 - 59 яшь) 58,3 процентка кадәр;<br>системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче өлкән яшьтәге гражданнар өлешен (хатын-кызлар 55 - 79 яшь, ир-атлар 60 - 79 яшь) 29,2 процентка кадәр. |

1 нче ярдәмче программаның I бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«I. Дәүләт сәясәтенең өстенлекле юнәлешләре һәм максатлары, 1 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру өлкәсенең гомуми характеристикасы

Әлеге 1 нче ярдәмче программа «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законны, «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» 2007 елның 4 декабрендәге 329-ФЗ номерлы Федераль законны, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Уңайлы мохит» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2019 елның 29 мартындагы 363 номерлы карарын, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясендә физик культураны һәм спортны үстерү стратегиясен раслау турында 2020 елның 24 ноябрендәге б-3081 номерлы боерыгын, «Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын, «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 - 2025 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 23 декабрь, 1023 нче карарын исәпкә алып эшләнде.»;

Физик культура һәм массакүләм спорт тармагында дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру максатлары төбәкнең социаль-икътисадый үстеше фаразы белән билгеләнде, алар Татарстан Республикасы гражданнары тарафыннан сәламәт яшәү рәвеше алып бару, аларны системалы рәвештә физик культура һәм массакүләм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итү өчен кирәкле шартлар тудыруны күздә тота.

Әлеге программа документларында физик культура һәм спорт өлкәсендә түбәндәге өстенлекле юнәлешләр күрсәтелә:

Татарстан Республикасы халкының төрле яшь категорияләрен һәм төркемнәрен даими рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итү;

Татарстан Республикасы халкының физик әзерлеге дәрәҗәсен арттыру;

спорт объектларыннан, шул исәптән өлкән яшьтәгеләр, сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затлар һәм инвалидларның файдалана алуын арттыру.

1 нче ярдәмче программа бурычлары:

гражданнарның физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүгә һәм сәламәт яшәү рәвеше алып баруга мотивациясен арттыру;

физик культура һәм спорт инфраструктурасын үстерү, шул исәптән сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затлар һәм инвалидлар өчен;

«Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) бөтенроссия физкультура-спорт комплексын һәм аны үтәүгә әзерләнү системасын популярлаштыру;

һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирүче мәгариф оешмалары базасында студентлар спортын үстерү.

Массакүләм спорт өлкәсендә дәүләт сәясәтенең өстенлекле юнәлешләре һәм максатлары соңгы дистә елда төзелгән норматив хокукый базада чагылыш тапты. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 24 ноябрендәге 3081-р номерлы боерыгы белән расланган 2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясендә физик культураны һәм спортны үстерү стратегиясе төп документлар булып тора. Моннан тыш, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 5 февралендәге 164-р боерыгы белән 2025 елга кадәр Россия Федерациясендә өлкән буын гражданнары мәнфәгатьләрендә гамәлләр стратегиясе расланды, анда урта һәм өлкән яшьтәге гражданнарның сәламәтлеген ныгыту өчен физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә аерым әһәмият бирелә. Россия Федерациясе Президентының 2014 елның 24 мартындагы 172 номерлы Указы белән 2014 елның 1 сентябреннән «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) бөтенроссия физкультура-спорт комплексы гамәлгә кертелде. Балалар-яшүсмерләр, мәктәп һәм студентлар спортын үстерү, шулай ук Россия Федерациясе спорт җыелма командалары өчен перспектив спортчылар санын һәм спорт резервын арттыру өчен өстәмә хокукый шартлар булдырылды.

1 нче ярдәмче программа кысаларында «Спорт - яшәү нормасы» федераль проекты чаралары, шул исәптән халыкның барлык категорияләре һәм төркемнәре: балалар һәм укучы яшьләр (студентлар), урта һәм өлкән яшьтәге төркем затлары, инвалидлар һәм сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән затлар, шул исәптән инвалид балалар өчен физкультура һәм комплекслы физкультура чаралары гамәлгә ашырылды. Мәгариф системасында Татарстан Республикасы халкы арасында «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексын гамәлгә кертү һәм популярлаштыру эше дәвам итте. Студентлар спортын үстерүгә зур игътибар бирелә.

Татарстан Республикасы халкын физик культура һәм массакүләм спорт белән системалы шөгыльләнүгә җәлеп итү максатларында спорт инфраструктурасын модернизацияләү һәм төрле яшь категорияләрендә һәм төркемнәрендә халык өчен спорт корылмаларыннан файдалану мөмкинлеген арттыру буенча эш алып барылды.

Физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүче гражданнарның өлеше 2016 ел белән чагыштырганда 15,6 проценттан 52,9 процентка кадәр, ягъни 37 процентка диярлек артты. Инвалидлар һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затлар арасында әлеге күрсәткеч 2021 ел нәтиҗәләре буенча 33,2 процент тәшкил иткән (исәп-хисап физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә каршы килмәгән инвалидлар саныннан ясалган).

2017 - 2021 елларда Татарстан Республикасында «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексының сынаулар (тестлар) нормативларын үтәү буенча 51 үзәк булдырылды, 387 урын тест үткәрү өчен.

Физкультура чараларының һәм спорт чараларының бердәм календарь планы нигезендә Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы тарафыннан ел саен 800 дән артык физкультура чарасы уздырыла, шул исәптән балалар һәм укучылар арасында да.

2013 елдан 2021 елга кадәр уздырыла торган чаралар саны 45 процентка диярлек арткан.

Дәүләт федераль һәм төбәк программалары төзи, җайлашу спортын үстерүгә юнәлтелгән сынау проектларын гамәлгә ашыра. Россия Федерациясенең закон базасында инвалидларның һәм сәламәтлеге шартларында чикләүләре булмаган кешеләрнең хокукларын тигезләүче документлар барлыкка килә. Әмма хәзерге вакытта хокуклар тигезлеге күбесенчә аларны гамәли гамәлгә ашыруның реаль шартлары булмау сәбәпле декларатив характерда була, чөнки алар күбесенчә Россия Федерациясе төбәкләрендә, аерым алганда, Татарстан Республикасында, шулай ук муниципаль дәрәҗәдә дә адаптив спортны үстерүгә идарә итү проблемасының фәнни-гамәли яктан җитәрлек дәрәҗәдә эшләнеп бетмәве белән аңлатыла.

Республикада адаптив физик культураны һәм спортны үстерү түбәндәге юнәлешләр буенча гамәлгә ашырыла:

массакүләм адаптив физик культураны үстерү;

Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе җыелма командалары өчен спортның адаптив төрләре буенча спорт резервын әзерләү;

югары казанышларга җайлашу спортына ярдәм итү.

Татарстан Республикасында 286 394 инвалид зат яши, алар арасында 16 793 бала һәм инвалид яшүсмер, 91 216 инвалид һәм сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән затлар спорт белән шөгыльләнә алмый.

Татарстан Республикасының 45 муниципаль берәмлеге территориясендә инвалидларны һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затларны адаптив физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүгә җәлеп итү эше алып барыла. Иң күп эш Казан, Чаллы, Әлмәт, Түбән Кама шәһәрләрендә һәм Татарстан Республикасының Азнакай, Саба, Мамадыш һәм Лаеш муниципаль районнарында башкарыла.

Татарстан Республикасында спорт корылмаларының һәм спорт мәктәпләренең киң челтәре нәтиҗәле эшли, югары дәрәҗәдәге бөтенроссия һәм халыкара ярышлар уңышлы уздырыла, халыкның киң даирәсе арасында физкультура-сәламәтләндерү эшенең яңа формалары кертелә, спартакиада хәрәкәте үсә.

"Уңайлы мохит" яшәү тирәлеге булдыру буенча федераль программа һәм республика ярдәмче программасы кысаларында 2011 елдан бирле республиканың эре шәһәрләрендә 57 спорт объекты тулысынча җайлаштырылган, 2017 елда тагын 7 спорт объекты җайлаштырылган (2011 елда - 82,0 млн. сумга 14 объект, 2014 елда - 62,6 млн. сумга 17 объект, 2015 елда - 20,0 млн. сумга 16 объект, 2016 елда - 9,7 млн. сумга 10 объект).

Инвалидлар һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен адаптив физик культура дәресләре Татарстан Республикасының 142 учреждениесендә, спорт комплексларында оештырыла.

2010 елдан 2021 елга кадәр өч спорт федерациясе төзелгән һәм кабат аккредитацияләнгән:

Татарстан Республикасы сукырлар спорты федерациясе;

Татарстан Республикасы таяну-хәрәкәт аппараты бозылган затлар категориясе федерациясе;

Татарстан Республикасының чукраклар спорты федерациясе.

Татарстан Республикасы Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан беркетелгән төп паралимпия спорт төрләрен үстерә:

кышкы дисциплиналар: биатлон, чаңгы узышлары (терәк-хәрәкәт аппараты бозылган затлар спорты);

җәйге дисциплиналар: бочча, коляскаларда баскетбол (терәк-хәрәкәт аппараты бозылган затлар спорты), голбол һәм мини-футбол 5×5 (күрү сәләте бозылган категориядәге затлар спорты).

Россия Федерациясе җыелма командаларына һәм Татарстан Республикасы җыелма командасына паралимпия, сурдлимпия спорт төрләре буенча резерв әзерләүче терәк оешмалары сыйфатында «Спорт әзерлеге үзәге» дәүләт автоном учреждениесе һәм «Республика спорт-адаптив мәктәп» дәүләт бюджет учреждениесе билгеләнде.

Массакүләм адаптив спортны үстерү эшен оештыру «Татарстан Республикасы инвалидларының физкультура-спорт җәмгыяте» иҗтимагый оешмасы (алга таба - Татарстан Республикасы инвалидларының ФСО) һәм спорт төрләре буенча федерацияләр белән үзара хезмәттәшлектә Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2015 елда «Республика спорт-җайлашу мәктәбе» дәүләт бюджет учреждениесе төзү адаптив физик культураны һәм спортны үстерү өчен куәтле этәргеч булды. Хәзерге вакытта мәктәптә чукраклар, сукырлар, терәк-хәрәкәт аппараты зарарланган һәм интеллектуаль бозылышлары булган затлар спорты бүлекләре эшли.

Эш тәҗрибәсен, адаптив спорт төрләрен үстерү өлкәсендә 6 - 18 яшь категориясендә шөгыльләнүче балалар һәм инвалид яшүсмерләрнең кадрлар потенциалы һәм перспективалы составы исәпкә алынып, адаптив мәктәп базасында икенче этап белән түбәндәге бүлекчәләр ачылды: 2017 елда - Чаллы һәм Әлмәт шәһәрләрендә; 2018 елда - Лаеш, Мамадыш һәм Саба муниципаль районнарында.

2021 елда Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы инвалидларының физкультура-спорт җәмгыяте белән берлектә түбәндәгеләр уздырылды:

төрле категориядәге инвалидлар арасында чаңгы ярышлары, төрле категориядәге инвалидлар арасында өстәл теннисы, сукырлар спортының өстәл теннисы, сукырлар спортының хатын-кызлар командалары арасында голбол, сукырлар спортының ир-атлар командалары арасында голбол, 5×5 В1 футбол (тоталь скуырлар), 5×5 В2 + В3 футбол (начар күрүчеләр), терәк-хәрәкәт аппараты зарарланган затлар спорты боччасы, төрле категориядәге инвалидлар арасында җиңел атлетика, төрле категориядәге инвалидлар арасында йөзү, төрле категориядәге инвалидлар арасында армрестлинг, чукраклар спортының ирекле көрәше, чукраклар спортының грек-рим көрәше, төрле категориядәге инвалидлар арасында рус шашкасы, төрле категориядәге инвалидлар арасында халыкара шашка, төрле категориядәге инвалидлар арасында шахматлар буенча 17 Татарстан Республикасы чемпионаты;

төрле категориядәге инвалидлар арасында чаңгы ярышлары, төрле категориядәге инвалидлар арасында өстәл теннисы, сукырлар спорты кызлары арасында голбол, сукырлар спорты егетләре арасында голбол, 5×5 B1 футбол (тоталь сукырлар), 5×5 B2 + B3 футбол (начар күрүчеләр), терәк-хәрәкәт аппараты зарарланган затлар спорты боччасы, төрле категориядәге инвалидлар арасында җиңел атлетика, төрле категориядәге инвалидлар арасында йөзү, чукраклар спортының ирекле көрәше, чукраклар спортының грек-рим көрәше буенча 11 Татарстан Республикасы беренчелеге;

3 бөтенроссия ярышлары:

2021 елның 24 сентябреннән 26 сентябренә кадәр Байлар Сабасы шәһәр тибындагы поселогында терәк-хәрәкәт аппараты зарарланган затлар спорты буенча һәм интеллектуаль бозылышлары булган затлар спорты буенча өстәл теннисыннан бөтенроссия ярышлары (Татарстан кубогы) уздырылды. Ярышларда 90 спортчы, шулардан 57 ир-ат һәм 33 хатын-кыз; Россиянең түбәндәге регионнарыннан командалар составлары катнашты: Архангельск өлкәсе, Вологодск өлкәсе, Воронеж өлкәсе, Красноярск крае, Новосибирск өлкәсе, Башкортостан Республикасы, Карелия Республикасы, Татарстан Республикасы, Самара өлкәсе, Саратов өлкәсе, Чуваш Республикасы, Удмурт Республикасы;

2021 елның 2-4 декабрендә Бөгелмә шәһәрендә Ирекле һәм грек-рим көрәше дисциплиналарында чукраклар спорты буенча бөтенроссия ярышлары узды;

2021 елның 1 декабреннән 10 декабренә кадәр Татарстан Республикасының 10 муниципаль районында Инвалидлар декадасы кысаларында чаралар үткәрелде.

2021 елгы чараларда Татарстан Республикасының 24 районыннан барлыгы 1 000нән артык  кеше катнашты.

Халыкара һәм бөтенроссия ярышларында катнашу нәтиҗәләре буенча республика спортчылары төрле дәрәҗәдәге 68 дән артык медаль яулады.

2021 елда Россия җыелма командалары исемлекләренә Татарстан Республикасы җыелма командасының 396 әгъзасы һәм 49 кандидат керде.

300дән артык спортчы тренировка чараларына, бөтенроссия һәм халыкара ярышларга командировкага җибәрелә. Татарстан Республикасы инвалид спортчылары Россия, Европа, дөнья чемпионатларында, Паралимпия һәм Сурдлимпия уеннарында тотрыклы рәвештә җиңү яулап килә.

Татарстан Республикасында халыкны физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итү буенча максатчан эш алып барыла.

2021 елның февралендә Казан шәһәрендә һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә «Россия чаңгы юлы - 2021» XXXIX Бөтенроссия массакүләм чаңгы ярышлары һәм «Татарстан чаңгы юлы - 2021» республика массакүләм чаңгы ярышлары үткәрелде. Чаралар Татарстан Республикасының 24 муниципаль районында һәм Казан һәм Яр Чаллы шәһәрләрендә уздырылды, аларда 93 716 кеше катнашты.

2021 елның 18 сентябрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә «Татарстан кроссы - 2021» республика массакүләм ярышлары үткәрелде. Җиңел атлетика ярышлары стартларында барлыгы 18 500 кеше катнашты.

Республиканың барлык муниципаль берәмлекләрендә гадәттәгечә А.В.Тарасов исемендәге «Алтын алка» бөтенроссия яшь хоккейчылар клубы ярышлары үткәрелде. Катнашучыларның гомуми саны 6 750 кеше тәшкил итте.

Республиканың авыл җирлекләрендә һәм торак пунктларында ел саен футбол буенча «Күн туп» бөтенроссия ярышлары уздырыла. Барлыгы 2021 елда аларда 260 тан артык команда катнашты, якынча 5 000 катнашучы җәлеп ителде, шул исәптән 8 хатын-кыз командасы.

2021 елда бөтенроссия ярышларында катнашу йомгаклары буенча Татарстан Республикасы командалары түбәндәге югары нәтиҗәләргә иреште:

Кукмара шәһәреннән «Ягуар» командасы Смоленск шәһәрендә А.В.Тарасов исемендәге «Алтын алка» хоккей клубы бөтенроссия финал ярышларында (2006 - 2007 елгы яшүсмерләр арасында) көмеш медаль яулады;

Казан шәһәреннән «Ак бүре» командасы Түбән Новгород шәһәрендә А.В.Тарасов исемендәге «Алтын алка» хоккей клубы бөтенроссия финал ярышларында (2008 - 2009 елгы яшүсмерләр арасында) җиңүче булды;

Кукмара шәһәреннән «Арслан» командасы Әстерхан шәһәрендә А.В.Тарасов исемендәге «Алтын алка» хоккей клубы бөтенроссия финал ярышларында (2010 - 2011 елгы яшүсмерләр арасында) бронза медаль яулады;

Биектау муниципаль районының Биектау авылыннан «Биектау» командасы Чайковский шәһәрендә авыл командалары арасында А.В.Тарасов исемендәге «Алтын алка» хоккей клубының финал ярышларында (2006 - 2007 елгы егетләр) бронза медальләр яулады;

Алабуга шәһәреннән «Урман бал кортлары» командасы Салават шәһәрендә хәрби хезмәткә чакырганга кадәрге яшьтәге командалар (2005 - 2006 еллар) арасында А.В.Тарасов исемендәге «Алтын алка» хоккей клубы бөтенроссия финал ярышларында бронза призеры булды;

Зеленодольск шәһәреннән «3 нче спорт мәктәбе» командасы - 2006 - 2007 елгы егетләр командалары арасында Евпатория шәһәрендә футбол буенча «Күн туп» бөтенроссия финал ярышларында җиңүче, Волгоград шәһәрендә ярышлар суперфиналының бронза призеры булды;

Казан шәһәренең «Вахитов районының Олимпия резервы спорт мәктәбе» командасы - 2008 - 2009 елгы егетләр командалары арасында Волжск шәһәрендә футбол буенча «Күн туп» бөтенроссия финал ярышларында җиңүче;

Яр Чаллы шәһәреннән «Төзүче» командасы - 2010 - 2011 елгы кызлар командалары арасында Салават шәһәрендә футбол буенча «Күн туп» бөтенроссия ярышларының финал турнирында җиңүче.

Ел дәвамында Татарстан Республикасы дәүләт хезмәткәрләре Спартакиадасы кысаларында ярышлар узды. Дәүләт хезмәткәрләре арасында ярышлар 9 спорт төре буенча үткәрелде, аларда 27 министрлык һәм ведомство хезмәткәрләре катнашты.

Дәүләт хезмәткәрләре спртакиадасы йомгаклары буенча түбәндәге командалар призлы урыннар алды:

I урын - Татарстан Республикасы Президенты Аппараты командасы;

II урын - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты командасы;

III урын - Федераль казначылык Татарстан Республикасы буенча идарәсе командасы.

2018 елда Татарстан Республикасында «TIMERMAN» спорт чараларының комплекслы программасы булдырылды, ул җиде спорт төре буенча ярышларны үз эченә ала: җиңел атлетика һәм чаңгы ярышлары, йөзү һәм велогонка сериясе, триатлон, биатлон һәм спорт ориентлашуы. Стартларда профессиональ спортчылар да, һәвәскәрләр дә катнаша. 2021 елда Казан, Әлмәт, Яр Чаллы, Свияжск шәһәрләрендә һәм Байлар Сабасы шәһәр тибындагы поселогында 12 чара үткәрелде, аларда Россиянең 60 тан артык төбәгеннән 28 150 спортчы һәм сәламәт яшәү рәвешен яратучылар катнашты. Иң масштаблы чара - «Ак Барс Банк Казан марафоны», ул 1-2 майда булды, Казан шәһәренә Россиянең 67 төбәгеннән һәм 29 илдән 14 000 йөгерергә яратучылар килде.

2015 елдан «Яшел фитнес» социаль-спорт проекты гамәлгә ашырыла. Проект сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга, сәламәтлекне саклауга һәм җәмәгать урыннары территорияләрендә һәм торак йортларга якын территорияләрдә төрле яшь категорияләрдәге халыкны физик активлыкка җәлеп итүгә юнәлдерелгән. «Яшел фитнес» проекты федераль дәрәҗәдә Россиянең 110 шәһәрендә (43 регионда) гамәлгә ашырылган флагман проектларның берсе, анда 700 000 нан артык кеше катнашты. Республикада 2021 ел сезонында 1 500 чара үткәрелде, аларда якынча 100 000 кеше катнашты.

2021 елда Татарстан Республикасында «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (алга таба – ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексы кысаларында халыкны тестлаштыру эше дәвам итте. Сынаулар (тестлар) нормативларын үтәү Татарстан Республикасы шәһәрләрендә һәм районнарында 51 тест үзәге базасында үткәрелде.

2021 ел йомшаклары буенча ГТО комплексы сынаулары (тестлары) нормативларын үтәүдә катнашкан халыкның гомуми санынннан ГТО комплексы сынаулары (тестлары) нормативларын мактау билгеләренә үтәгән халык өлеше 65,8 процент тәшкил итте, 70 531 билге алынды, 107 216 кеше катнашты.

Ел дәвамында эш республикада яшәүчеләрнең нормативларын үтәүдә онлайн- һәм турыдан-туры катнашу режимында алып барылды.

ГТО комплексының кышкы фестивале уңышлы үткәрелде. Фестивальнең сайлап алу турларында 17 000 кеше катнашты.

2021 елның апрелендә гаилә командалары арасында ГТО фестивале үткәрелде. Түбән Кама, Саба, Спас муниципаль районнары командалары җиңүче булды.

2021 елның мартыннан маена кадәр ГТО бөтенсоюз комплексын төзүнең 90 еллыгына һәм Туган телләр һәм халык бердәмлеге елына багышланган республика балалар проектлары конкурсы үткәрелде. Рәсем конкурсына бөтен республикадан 374 проект эше кергән.

2021 елның июлендә «Сабантуй ГТО» видеороликлар конкурсының республика этабы тәмамланды. Катнашучылар Сабантуй өчен традицион булган ГТО нормативын үтәделәр - 16 кг гер күтәрү һәм ике аяклы озынлыкка сикерү. Күнегүләрне районның истәлекле урыннары фонында һәм милли костюмда башкару кирәк иде. Шулай ук ГТО комплексына багышланган чаралар үткәрелде: “ГТО - бөтен гаилә белән”, “ГТО - яшь тән һәм җан”, “ГТО билгесе белән 1 сыйныфка”, ГТО комплексының җәйге фестивале, “ГТО белән Яңа ел”.

Социаль проектлар кысаларында 2021 елда “Россия пенсионерлары берлеге” бөтенроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлеге һәм аның территориаль идарәләре тарафыннан, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы белән берлектә, муниципаль берәмлекләрдә 1 000нән артык чара уздырылды, аларда 40 000 өлкән яшьтәге кеше катнашты. Өлкән яшьтәге кешеләрдә сәламәтлекне саклау һәм ныгытуга, авыруларны профилактикалауга, физкультура-савыктыру дәресләренә ихтыяҗның артуы күзәтелә. Моңа Татарстан Республикасының һәр муниципаль берәмлегендә спорт белән шөгыльләнү өчен тудырылган шартлар, физкультура-спорт чаралары үткәрү дә ярдәм итә. 2021 елда физкультура-спорт чараларында өлкән яшьтәге 16 115 кеше катнашты.

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Профсоюзлар федерациясе һәм республиканың тармак профсоюзлары ярдәмендә “Спартак-Татарстан” физкультура-спорт җәмгыяте тарафыннан учреждениеләрдә, оешмаларда, предприятиеләрдә һәм берләшмәләрдә физкультура-сәламәтләндерү эше оештырылды.

2021 елда барлык милек рәвешләрендәге предприятиеләр хезмәткәрләре арасында спорт юнәлешендәге 23 дән артык чара үткәрелде. Ел дәвамында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең спорт объектларында «Сәламәтлек-2021» спартакиадасы үткәрелде. Спартакиада гадәттәгечә өч этапта уздырыла: 1 этап - предприятие һәм оешма эчендә, 2 этап - тармак предприятиеләре һәм оешмалары арасында, 3 этап - тармакара финал ярышлар. Спартакиада программасында - чаңгы ярышлары, пуля ату, өстәл теннисы, волейбол, мини-футбол, җиңел атлетика, шахмат, шашка, дартс, стритбол ярышлары. «Спартак-Татарстан» физкультура-спорт җәмгыяте хезмәттәшлек итә торган иң актив предприятиеләр - А.П.Обыденнов исемендәге Казан автотранспорт техникумы, «Татхимфармпрепараты» АҖ, Казан шәһәренең ПАТП-2 МУП, «Радиоэлектроника» НПО, «Түбән Кама Нефтехим» ГАО, «Казан дары заводы» КГКПЗ ФКП, «ЧелныБройлер» ҖЧҖ, «Метроэлектротранс» МУП, «Госкорпорация по ОрВД» ФГУП «Татаэронавигация» филиалы һәм башкалар.

Балалар һәм яшүсмерләр катнашындагы ярышларның яңа юнәлешләренә дә зур игътибар бирелә. 2021 елның мартында Казан шәһәрендә Ишкәкле спорт төрләре үзәге базасында нәфис гимнастика буенча «Спартак-Татарстан» физкультура-спорт җәмгыяте бүлегенең «Mickey Mouse Cup» III традицион ачык республика турниры үткәрелде. Турнирда Әлмәт, Йошкар-Ола, Монино, Казан, Ногинск, Пенза, Самара, Санкт-Петербург, Ульяновск шәһәрләреннән һәм Биектау муниципаль районыннан 23 команда катнашты. Ярышларда 435 гимнаст катнашты.»;

1 нче ярдәмче программаның II бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. 1 нче ярдәмче программаның төп максатлары һәм бурычлары,
чаралар, көтелә торган соңгы нәтиҗәләрнең тасвирламасы, аны гамәлгә ашыру
вакытлары һәм этаплары

1 нче ярдәмче программаның максаты - Татарстан Республикасы халкын физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүгә мотивацияләүне арттыру, сәламәт яшәү рәвешен алып бару.

Куелган максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү күздә тотыла:

1. Татарстан Республикасы халкының төрле категорияләрен һәм төркемнәрен физик тәрбияләү системасын камилләштерү, алар арасында инвалидлыгы булган затлар категорияләре, авыл территорияләрендә яшәүчеләр, барлык милек рәвешләрендәге предприятиеләр хезмәткәрләре һ.б.

2. Массакүләм спорт өчен, шул исәптән сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән инвалидлар һәм затлар өчен һәркем файдалана алырлык спорт инфраструктурасын тәэмин итү.

3. «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексын һәм аны үтәүгә әзерләнү системасын популярлаштыру;

4. Һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирүче мәгариф оешмалары базасында студентлар спортын үстерү.

Куелган максатның масштаблылыгы чаралар комплексын эшләүне таләп итә.

1 нче ярдәмче программа сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга, сәламәтлекне ныгытуга, Татарстан Республикасы халыкының барлык яшь категорияләре һәм төркемнәренең физик активлыгын һәм әзерлеген күтәрүгә, тулысынча ял итү һәм сәламәт ял итү өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән чараларны үтәүне күздә тота.

Күрсәтелгән чараларны гамәлгә ашыру Татарстан Республикасы халкының сәламәтлеген ныгыту өчен шартлар тудырырга, республикадагы демографик вәзгыятьне яхшыртырга, массакүләм спортны үстерергә һәм популярлаштырырга, Татарстанның спорт имиджын киләчәктә халыкара дәрәҗәдә ныгыту максатларында җәмгыятьнең төрле катламнарын физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүгә җәлеп итәргә мөмкинлек бирәчәк.

1 нче ярдәмче программа чараларын тормышка ашыру 2025 елга түбәндәгеләрне арттыруга ирешергә мөмкинлек бирәчәк:

системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче гражданнар өлешен 62,1 процентка кадәр;

«Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексының сынаулар (тестлар) нормативларын тапшыруда катнашкан халыкның гомуми санында «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексының сынаулар (тестлар) нормативларын үтәгән Татарстан Республикасы халкы өлешен 57,5 процентка кадәр, шулардан укучылар һәм студентлар өлешен 71,0 процентка кадәр;

сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затлар һәм инвалидларның гомуми санында физик культура һәм спорт белән системалы рәвештә шөгыльләнүче әлеге категориядәге затлар өлешен 30,0 процентка кадәр;

Татарстан Республикасы халкының гомуми санында даими рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче авыл халкы өлешен 58,3 процентка кадәр;

системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче балалар һәм яшьләр өлешен (3 - 29 яшь) 88,5 процентка кадәр;

системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче гражданнарның өлешен (хатын-кызлар 30 - 54 яшь, ир-атлар 30 - 59 яшь) 58,3 процентка кадәр;

системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче өлкән яшьтәге гражданнар өлешен (хатын-кызлар 55 - 79 яшь, ир-атлар 60 - 79 яшь) 29,2 процентка кадәр.

1 нче ярдәмче программаның максаты, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм 1 нче ярдәмче программа чаралары буенча финанслау аңа теркәлгән кушымтада китерелде.

1 нче ярдәмче программаны тормышка ашыруның гомуми срогы: 2021 – 2025 еллар.»;

1 нче ярдәмче программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. 1 нче ярдәмче программаның
ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

1 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 1 367 880,3 мең сум тәшкил итәчәк, шулардан Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән - 1 177 595,2 мең сум, шул исәптән:

2019 елда - 318 916,6 мең сум;
2020 елда - 144 457,6 мең сум;
2021 елда - 300 996,9 мең сум;
2022 елда - 102 756,4 мең сум;
2023 елда - 103 214,7 мең сум;
2024 елда - 103 626,5 мең сум;
2025 елда - 103 626,5 мең сум.

Федераль бюджет акчасы исәбеннән планлаштырыла торган финанслау 190 285,1 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:

2019 елда - 69 341,1 мең сум;
2020 елда - 45 478,3 мең сум;
2021 елда - 14 868,9 мең сум;
2022 елда - 20 870,3 мең сум;
2023 елда - 21 353,1 мең сум;
2024 елда - 9 186,7 мең сум;
2025 елда - 9 186,7 мең сум.

1 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен тәгаенләнергә тиеш.

Федераль бюджет, җирле бюджетлар һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчасы күләмнәре ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк»;

1 нче ярдәмче программага кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

«2019 - 2024 елларга югары казанышлар спортын һәм спорт резервын әзерләү системасын үстерү» ярдәмче программасында (алга таба - 2 нче ярдәмче

программа):

2 нче ярдәмче программа исемендә «2019 - 2024» саннарын «2019 - 2025» саннарына алмаштырырга;

2 нче ярдәмче программа паспортында:

«Ярдәмче программа исеме» юлында «2019 - 2024» саннарын «2019 - 2025» саннарына алмаштырырга;

«Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары» юлында «2019 - 2024» саннарын «2019 - 2025» саннарына алмаштырырга;

«Еллар һәм финанслау чыганаклар буенча бүлеп, 2 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, 2 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре | 2 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 14 166 814,8 мең сум тәшкил итә, шуларның 13 999 258,5 мең сумы Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән, шул исәптән:<br>2019 елда - 2 086 737,9 мең сум;<br>2020 елда - 2 073 931,1 мең сум;<br>2021 елда - 2 480 285,2 мең сум;<br>2022 елда – 1 552 547,3 мең сум;<br>2023 елда – 1 733 133,6 мең сум;<br>2024 елда - 2 036 311,7 мең сум;<br>2025 елда - 2 036 311,7 мең сум.<br>Федераль бюджет акчасы исәбеннән планлаштырыла торган финанслау 167 556,3 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>2019 елда – 0,0 мең сум;<br>2020 елда - 18 369,2 мең сум;<br>2021 елда - 26 734,1 мең сум;<br>2022 елда - 28 319,5 мең сум;<br>2023 елда - 28 319,5 мең сум;<br>2024 елда - 32 907,0 мең сум;<br>2025 елда - 32 907,0 мең сум.<br>2 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен тәгаенләнергә тиеш.<br>Федераль бюджет, җирле бюджетлар һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчасы күләмнәре ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк»; |

«2 нче ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «2 нче ярдәмче программа максатларын һәм | 2 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру нәтиҗәсендә 2025 елга түбәндәгеләрне арттыруга ирешергә мөмкинлек бирәчәк: |

| | |
|---|---|
| бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Россия Федерациясе спорт җыелма командаларына кандидатлар исемлекләренә кертелгән спортчыларның санын 580 кешегә кадәр;<br>физик культура һәм спорт өлкәсендәге оешмаларның гомуми санында, шул исәптән сәламәтлеге һәм инвалидлары мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен спорт әзерлегенең федераль стандартлары нигезендә спорт әзерлеге буенча хезмәтләр күрсәтүче оешмалар өлешен 100 процентка кадәр;<br>спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда спортны камилләштерү этабында шөгыльләнүчеләрнең гомуми санын 25 процентка кадәр»; |

2 нче ярдәмче программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. 2 нче ярдәмче программаның
ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

2 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 14 166 814,8 мең сум тәшкил итә, шуларның 13 999 258,5 мең сумы Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән, шул исәптән:

2019 елда - 2 086 737,9 мең сум;
2020 елда - 2 073 931,1 мең сум;
2021 елда - 2 480 285,2 мең сум;
2022 елда – 1 552 547,3 мең сум;
2023 елда – 1 733 133,6 мең сум;
2024 елда - 2 036 311,7 мең сум;
2025 елда - 2 036 311,7 мең сум.

Федераль бюджет акчасы исәбеннән планлаштырыла торган финанслау 167 556,3 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:

2019 елда – 0,0 мең сум;
2020 елда - 18 369,2 мең сум;
2021 елда - 26 734,1 мең сум;
2022 елда - 28 319,5 мең сум;
2023 елда - 28 319,5 мең сум;
2024 елда - 32 907,0 мең сум;
2025 елда - 32 907,0 мең сум.

2 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен тәгаенләнергә тиеш.

Федераль бюджет, җирле бюджетлар һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчасы күләмнәре ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк»;

2 нче ярдәмче программага 1 нче кушымтаны, аның нумерция башисемендә

«1 нче кушымта» сүзләрен «кушымта» сүзенә алмаштырып, яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

«2019 - 2024 елларга физик культура һәм спорт өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерү» ярдәмче программасында (алга таба - 3 нче ярдәмче программа):

3 нче ярдәмче программа исемендә «2019 - 2024» саннарын «2019 - 2025» саннарына алмаштырырга;

3 нче ярдәмче программа паспортында:

«Ярдәмче программа исеме» юлында «2019 - 2024» саннарын «2019 - 2025» саннарына алмаштырырга;

«3 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру сроклары» юлында «2019 - 2024» саннарын «2019 - 2025» саннарына алмаштырырга;

«Еллар һәм финанслау чыганаклары буенча бүлеп, 3 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм финанслау чыганаклары буенча бүлеп, 3 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре | 3 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 343 967,4 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:<br>2019 елда - 61 802,1 мең сум;<br>2020 елда - 60 531,9 мең сум;<br>2021 елда - 62 767,1 мең сум;<br>2022 елда - 39 632,6 мең сум;<br>2023 елда - 39 698,7 мең сум;<br>2024 елда - 39 767,5 мең сум;<br>2025 елда - 39 767,5 мең сум.<br>3 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен тәгаенләнергә тиеш.<br>Федераль бюджет, җирле бюджетлар һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчасы күләмнәре ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк»; |

«3 нче ярдәмче программаның максатын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «3 нче ярдәмче программаның максатын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү | 3 нче ярдәмче программа чараларын тормышка ашыру 2025 елга түбәндәгеләрне арттыруга ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>«Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасында «Вакытында үтәлмәде» статусы белән хәбәрнамәләр өлешен 0 берәмлеккә кадәр;<br>Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарлары йөкләмәләренең гомуми күләмендә |

| | |
|---|---|
| индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан әлеге затлар тарафыннан үтәлү вакыты билгеләнгән тикшерү вакытларында үтәлгән әлеге йөкләмәләр өлешен 100 процентка кадәр;<br>Татарстан Республикасы законнарында, Татарстан Республикасы Президенты указларында, боерыкларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларында, боерыкларында бирелгән шәхсиләштерелгән йөкләмәләрнең гомуми санында Татарстан Республикасының әлеге норматив хокукый актларында бирелгән шәхсиләштерелгән йөкләмәләрнең Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан үтәлү өлешен 100 процентка кадәр»; |

3 нче ярдәмче программаның II бүлегендәге унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3 нче ярдәмче программаны тормышка ашыруның гомуми срогы: 2019 – 2025 еллар.»;

3 нче ярдәмче программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. 3 нче ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

3 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 343 967,4 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:

2019 елда - 61 802,1 мең сум;
2020 елда - 60 531,9 мең сум;
2021 елда - 62 767,1 мең сум;
2022 елда - 39 632,6 мең сум;
2023 елда - 39 698,7 мең сум;
2024 елда - 39 767,5 мең сум;
2025 елда - 39 767,5 мең сум.

3 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен тәгаенләнергә тиеш.

Федераль бюджет, җирле бюджетлар һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчасы күләмнәре ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк»;

3 нче ярдәмче программага кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

«2019 – 2025 елларга Татарстан Республикасында физик культураны һәм спортны үстерү» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү» ярдәмче программасында (алга таба - 4 нче ярдәмче программа):

4 нче ярдәмче программа исемендә «2019 - 2024» саннарын «2019 - 2025» саннарына алмаштырырга;

4 нче ярдәмче программа паспортында:

«Ярдәмче программа исеме» юлында «2019 - 2024» саннарын «2019 - 2025» саннарына алмаштырырга;

«4 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары» юлында «2019 - 2024» саннарын «2019 - 2025» саннарына алмаштырырга;

«Еллар һәм финанслау чыганаклар буенча бүлеп, 4 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr>
<td>«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, 4 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре</td>
<td>4 нче ярдәмче программаны финанслау күләме 20 361 429,03 мең сум тәшкил итә, шул исәптән федераль бюджетның фаразланган чаралары исәбеннән - 2 685 818,31 мең сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән - 17 629 610,72 мең сум, бюджеттан тыш чыганаклардан билгеләнгән тәртиптә җәлеп ителә торган - 46 000,0 мең сум.<br>(мең сум)
<table>
<tr><th rowspan="2">Ел</th><th rowspan="2">4 нче ярдәмче программа буенча чаралар күләме барлыгы</th><th colspan="3">Шул исәптән түбәндәгеләр акчасы</th></tr>
<tr><th>Татарстан Республикасы бюджеты</th><th>федераль бюджет</th><th>бюджеттан тыш чыганаклар</th></tr>
<tr><td>2019</td><td>2 282 574,9</td><td>1 950 269,3</td><td>332 305,6</td><td>0,0</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>6 690 766,38</td><td>5 931 298,38</td><td>759 468,0</td><td>0,0</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>2 969 844,35</td><td>2 694 709,64</td><td>275 134,71</td><td>0,0</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>2 502 853,4</td><td>2 053 333,4</td><td>449 520,0</td><td>0,0</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>2 915 390,0</td><td>2 000 000,0</td><td>869 390,0</td><td>46 000,0</td></tr>
<tr><td>2024</td><td>1 500 000,00</td><td>1 500 000,0</td><td>0,00</td><td>0,0</td></tr>
<tr><td>2025</td><td>1 500 000,0</td><td>1 500 000,0</td><td>0,00</td><td>0,0</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>20 361 429,03</td><td>17 629 610,72</td><td>2 685 818,31</td><td>46 000,0</td></tr>
</table>
4 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен тәгаенләнергә тиеш.<br>Федераль бюджет, җирле бюджетлар һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчасы күләмнәре ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк»;</td>
</tr>
</table>

«4 нче ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr>
<td>«4 нчы ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы</td>
<td>4 нче ярдәмче программа чараларын тормышка ашыру нәтиҗәсендә 2025 елга түбәндәгеләргә ирешү күздә тотыла:<br>100 мең кешегә исәпләнгән спорт корылмалары санын 323 берәмлеккә кадәр;<br>гражданнарның спорт корылмалары белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен, бер мәртәбә үткәрү сәләтеннән чыгып, 71,2 процентка кадәр;</td>
</tr>
</table>

| | |
|---|---|
| нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | спорт учреждениеләрен тәэмин итү өчен электр энергиясенең чагыштырма чыгымын (җылытыла торган 1 кв.метр мәйданга исәпләгәндә) – 1 кв.метрга 71,44 кВт × сәгать;<br>спорт учреждениеләрен тәэмин итү өчен җылылык энергиясенең чагыштырма чыгымын (җылытыла торган 1 кв.метр мәйданга исәпләгәндә) – җылытыла торган 1 кв.метр мәйданга 0,103 Гкал;<br>спорт учреждениеләрен тәэмин итү өчен салкын суның чагыштырма чыгымын (1 кешегә (персонал һәм йөрүчеләргә) исәпләгәндә) – 1 кешегә (персонал һәм йөрүчеләргә) 0,157 куб.метр;<br>спорт учреждениеләрен тәэмин итүгә табигый газның чагыштырма чыгымын (газ белән җылытыла торган мәйданның 1 кв.метрына исәпләгәндә) - газ ягып җылытыла торган мәйданның бер квадрат метрына 23,91 куб метр;<br>мәҗбүри энергетика тикшерүен узган Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына буйсынучы учреждениеләрнең өлешен 100 процентка кадәр;<br>Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының исәпкә алу приборлары белән җиһазландырылган ведомство буйсынуындагы учреждениеләре (урыннарны арендага алучы учреждениеләрне исәпкә алмыйча) өлешен 100 процентка кадәр»; |

4 нче ярдәмче программаның II бүлегендәге егерме тугызынчы абзацында «2019 - 2024» саннарын «2019 - 2025» саннарына алмаштырырга;

4 нче ярдәмче программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. 4 нче ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

4 нче ярдәмче программаны финанслау күләме 20 361 429,03 мең сум тәшкил итә, шул исәптән федераль бюджетның фаразланган чаралары исәбеннән - 2 685 818,31 мең сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән - 17 629 610,72 мең сум, бюджеттан тыш чыганаклардан билгеләнгән тәртиптә җәлеп ителә торган - 46 000,0 мең сум.

(мең сум)

| Ел | 4 нче ярдәмче программа буенча чаралар күләме барлыгы | Шул исәптән түбәндәгеләр акчасы | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | федераль бюджет | бюджеттан тыш чыганаклар |
| 2019 | 2 282 574,9 | 1 950 269,3 | 332 305,6 | 0,0 |
| 2020 | 6 690 766,38 | 5 931 298,38 | 759 468,0 | 0,0 |
| 2021 | 2 969 844,35 | 2 694 709,64 | 275 134,71 | 0,0 |
| 2022 | 2 502 853,4 | 2 053 333,4 | 449 520,0 | 0,0 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 2023 | 2 915 390,0 | 2 000 000,0 | 869 390,0 | 46 000,0 |
| 2024 | 1 500 000,0 | 1 500 000,0 | 0,00 | 0,0 |
| 2025 | 1 500 000,0 | 1 500 000,0 | 0,00 | 0,0 |
| Барысы | 20 361 429,03 | 17 629 610,72 | 2 685 818,31 | 46 000,0 |

4 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен тәгаенләнергә тиеш.

Федераль бюджет, җирле бюджетлар һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчасы күләмнәре ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк»;

4 нче ярдәмче программага 1, 2 нче кушымталарны яңа редакциядә (карарга теркәләләр) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин